**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

Әбсәләм ав.

№2 «30» январь 2026 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советының 2018 елның 23 маендагы 9 санлы карары белән расланган үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, 2009 елның 12 февралендәге «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында»гы 15-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 25 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»гы182 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы 994 санлы карарлары нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советының 2018 елның 23 маендагы 9 санлы карары белән расланган үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 бүлегенең 1 пунктында «15 389» санын «16928» санына алмаштырырга;

1.2. Нигезләмәгә 1 нче кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru/ һәм "Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталы" челтәр басмасында Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru (2013 елның 17 декабрендәге Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталын урнаштыру адресы буенча http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В.Кубашева

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советының 2018 елның 23 маендагы 9 санлы карары белән расланган үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыгын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфа атамасы | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | шәһәр тибындагы бистәләр нигезендә төзелгән авыл һәм шәһәр җирлекләрендә |
| | 12 төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 23 201 |